| | | |
|---|---|---|
| 0,ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.01.2022 ел Баулы шәһәре № 17

Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2017 елның 11 декабрендәге 504 номерлы «Кулланучылар кооперациясе оешмаларының Баулы муниципаль районы үзәгеннән - Баулы шәһәреннән 11 километр ераклыкта урнашкан Баулы муниципаль районының ерак һәм халкы аз санлы торак авыл пунктларына беренче чиратта кирәкле товарларны китерү белән бәйле чыгымнары өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» карарына (2018 елның 19 июнендәге 238 номерлы, 2019 елның1 ноябрендәге 305 номерлы, 2020 елның 188 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 нче номерлы «Юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар җитештерүче, эшләр башкаручы, хезмәтләр күрсәтүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары гамәлдән чыгуын тану турында»гы карары нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Баулы муниципаль районы башкарма комитетының 2017 елның 11 декабрендәге 504 номерлы «Кулланучылар кооперациясе оешмаларының Баулы муниципаль районы үзәгеннән - Баулы шәһәреннән 11 километр ераклыкта урнашкан Баулы муниципаль районының ерак һәм халкы аз санлы торак авыл пунктларына беренче чиратта кирәкле товарларны китерү белән бәйле чыгымнары өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» карарына (2018 елның 19 июнендәге 238 номерлы, 2019 елның1 ноябрендәге 305 номерлы, 2020 елның 188 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге

үзгәрешләрне кертергә:

1.2. пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
«Субсидия алучыларны сайлап алу үткәрелми»;

1.3. пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Бирелә торган субсидияләр турындагы мәгълүмат Баулы муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе Финанс министрлыгының бердәм порталында Россия Федерациясе Финанс министрлыгы һәм муниципаль финанс органнары өчен мондый техник мөмкинлекне гамәлгә ашырганнан соң урнаштырылырга тиеш.»;

2.1. пунктның а) пунктчасында "Баулы ш." сүзләреннән соң "факттагы чыгымнарны (алынмаган табышларны) раслый торган (аларга юл кәгазьләре һәм ягулык-майлау материаллары белән тәэмин итүгә шартнамә керә) документларның расланган күчермәләрен кушып" сүзләрен өстәргә»;

2.2. пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әгәр субсидия сайлап алу нәтиҗәләре буенча бирелә икән, сайлап алуда катнашучы сайлап алу үткәрү планлаштырыла торган айның 1нче көненә таләпләргә туры килергә тиеш, ә калган очракларда килешү төзү планлаштырыла торган айның беренче көненә түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:»;

түбәндәге эчтәлекле җиденче абзац өстәргә:

«дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки юридик зат булган сайлап алуда катнашучының баш бухгалтеры, сайлап алуда катнашучы булган индивидуаль эшкуар һәм товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик зат турында мәгълүматлар булмау (мондый таләпләр хокукый акт белән каралган очракта).»;

2.3. пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Субсидия алучыга субсидия бирү турындагы килешүгә кул кую һәм аны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты адресына җибәрү вакыты - 2 календарь көн.»;

2.7. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.7. Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Баулы муниципаль районы буенча территориаль бүлегендә ачылган шәхси счетыннан, Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яисә кредит оешмаларында субсидия алучыга ачылган исәп-хисап яки корреспондент счетына субсидияләр күчерүне гамәлгә ашыра.

Субсидия алучыга субсидия бирү срогы: комиссия тарафыннан субсидия бирү турында карар кабул ителгәннән соң ун эш көненнән дә соңга калмыйча, субсидия

алучы белән 2.3. пунктта билгеләнгән срокта, ләкин агымдагы елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча килешү төзү шарты белән.»;

2.10. пунктына түбәндәге өстәмәне кертергә:

«2.10. Субсидия бирүнең нәтиҗәсе булып Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Баулы муниципаль районы үзәгеннән – Баулы шәһәреннән 11 чакрымнан ераграк урнашкан авыл торак пунктларына беренче чиратта кирәкле товарларны китерү тора.»;

3.2. пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Бирелгән субсидияләр Баулы муниципаль районы бюджеты керемен\u04d9 субсидияләр алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар бирү фактларын ачыклау буенча Башкарма комитетның тиешле таләбе алынганнан соң 30 көн эчендә кире кайтарылырга тиеш.»;

3.5. пунктына түбәндәге өстәмәне кертергә:

«3.5. Башкарма комитет килешүдә билгеләнгән субсидияләр бирү нәтиҗәләренә ирешүгә һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны тәмамлау фактын чагылдыра торган вакыйгаларга, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формада субсидияләр бирү нәтиҗәләренә мониторинг үткәрә.».

2. Әлеге карарның 1 пунктының 3.5. пунктчасы нигезләмәләре 2023 елның 1 гыйнварыннан кулланыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында һәм сайтта (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров